**Программа учебной дисциплины**

**5.3. «Лексикология родного (татарского) языка»**

## 1. Цель освоения дисциплины

Целью освоения дисциплины является подготовка высококвалифицированного специалиста, обладающего глубокими теоретическими знаниями в области лексикологии родного (татарского) языка и умеющего применять их на практике.

## 2. Планируемые результаты освоения дисциплины

| № п/п | Компетенции | Знать | Уметь | Владеть |
|---|---|---|---|---|
| 1. | ПК-1 | пути исторического развития языка, в частности особенности развития разных ярусов его структуры и характер их взаимодействия в процессе развития; механизмы функционирования и тенденций развития родного и русского языков; теоретические основы лексикологии татарского литературного языка | использовать теоретические знания и практические умения и навыки в предметной области при решении профессиональных задач; объяснять особенности тех или иных единиц современного языка и характер их употребления на основе анализа их происхождения; излагать свои мысли на родном и русском языках в письменной и устной форме | навыками лексического разбора слов; навыками адекватного использования лексических ресурсов родного и русского языков; навыками работы с учебной, научной и справочной литературой |
| 2. | ПК-2 | теоретические основы лексического строя родного языка; нормы функционирования родного и русского языков; систему и | анализировать лексические единицы; самостоятельно пополнять и углублять лингвистические знания; применять полученные | лингвистической терминологией; навыками синхронического анализа лексических единиц родного языка; литературными нормами родного языка |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | структуру родного языка, роль родного языка в современном обществе | знания на практике; осуществлять целенаправленную воспитательную деятельность | |
| 3. | ПК-3 | лексические нормы родного языка | формировать развивающую образовательную среду для достижения личностных, предметных и метапредметных результатов обучения средствами преподаваемых учебных предметов | навыками использования лексических ресурсов родного и русского языков |

## 3. Содержание дисциплины

| № п/п | Тема | Кол-во часов | Вид | Содержание |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Татар теле лексикологиясенең өйрәнү предметы һәм бурычлары | 2 | Лекция | Лексикологиянең төп предметы һәм бурычы буларак лексиканың системалы характерга ия табигатен ачу, тасвирлау. Татар лексикасының хосусый мәсьәләләре: 1) лексик семантиканы өйрәнү (сүз мәгънәләренең табигате, төре һәм типлары; лексик берәмлекләрнең структурасы; лексик берәмлекләрнең категориаль мөнәсәбәтләре: күпмәгънәлелек, омонимия, синонимия, антонимия, семантик кыр һ.б.); 2) татар теленең сүзлек составын төп оппозицияләр буенча төркемләү (телнең үз сүзләре һәм алынмалар; актив һәм пассив (искергән һәм яңа) сүзләр; гомумхалык һәм кулланылышы чикле лексика (терминологик, диалекталь, жаргон лексика); стилистик нейтраль һәм үзенчәлекле сүзләр (китап сүзләре һәм сөйләм теле сүзләре һ.б.); 3) төп фразеологик берәмлекләрне системага салу; 4) сүзлекләрнең гомуми типологиясен эшкәртү һәм татар теленең төп тип сүзлекләрен тасвирлау. Лексикологиянең тармаклары (семасиология, этимология, |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | лексикография, фразеология, ономастика). |
| 2. | Семасиология | 2 | Лекция | Лексик семантика. Лексик мәгънә. Лексик мәгънәләрнең төрләре.<br>Бер мәгънәле һәм күп мәгънәле (полисемантик) сүзләр. Сүз мәгънәсенең үсеше (метафорага, метонимиягә, синекдохага, функция буенча күчешкә нигезләнгән күчерелмә мәгънәләр). Күпмәгънәлелек һәм аңа билгеләмә бирү (сүзнең бер үк вакытта берничә мәгънәгә ия булудан гыйбарәт семантик үзенчәлеге). Күпмәгънәлелекнең (полисемия) төрләре. Күпмәгънәле сүзләрнең семантик һәм стилистик функцияләре.<br>Омонимия. Омонимия күренешенә билгеләмә бирү. Омонимнарның барлыкка килү сәбәпләре. Омонимнарны төркемләү: тулы һәм өлешчә омонимнар, омофон, омографлар, омоформа, омоморфема. Омонимия һәм күпмәгънәлелек; семантик омонимнар барлыкка килү һәм аның сәбәпләре (экстралингвистик һәм лингвистик). Омонимнарның семантик һәм стилистик функцияләре.<br>Пароним сүзләр турында төшенчә. Пароним сүзләрнең буталу сәбәпләре. Паронимнарның стилистик функцияләре.<br>Синонимия. Синонимнарга билгеләмә бирү. Ономасиологик категория буларак синонимия. Синонимиянең мәгънәви асылы буларак лексик берәмлекләр эчтәлегенең эквивалентлыгы. Синонимик рәт, доминанта төшенчәләре. Синонимнарны төркемләү. Синонимнарны 3 нигездә: 1) бер-берсен алыштыра алу сәләтенә һәм мәгънәләренең туры килү дәрәҗәсенә карап, тулы һәм өлешчә синонимнарга бүлү; 2) функцияләренә карап, семантик (идеографик), стилистик һәм семантик-стилистик синонимнарга бүлү; 3) төзелешләренә карап, синонимнарны төрле тамырдан һәм бер тамырдан ясалган төрләргә бүлү. Синонимнарның функцияләре. Семантик функция (сүзне алыштыру һәм ачыклау). Ачыклау функциясенең контекстка бәйле булуы |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | (нейтраль контекст һәм дифференциацияләүче контекст). Синонимнарның стилистик функцияләре (стилистик бәяләү һәм стильне оештыру функцияләре). Синонимнарның барлыкка килүе. Антонимия. Антонимия күренешенә билгеләмә бирү. Антонимнарның семантик тиңдәш лексик берәмлекләрне иң соңгы чиктәге билге белән инкяр итү үзенчәлеге. Антонимнарны формаль һәм семантик үзенчәлекләренә карап структур һәм семантик яктан төркемләү. Структур яктан төрле тамырдан һәм бер тамырдан булган антонимнарга бүлү. Антонимия һәм полесимия. Антонимнарның функцияләре (каршы кую, бүлү, чиратлаштыру, бер сыйфатның, билгенең икенчегә әйләнүе; каршы куеп, бөтен күренешне белдерү). Даими һәм контекстуаль антонимнар. Стилистик фигура буларак антитеза. Оксюморон. |
| 3. | Телнең сүзлек составы ягыннан үзгәрешләр | 2 | Практ. | Телнең сүзлек составы турында төшенчә. Искергән сүзләр. Яңа сүзләрнең барлыкка килүе. Алынмалар. Сүзләрне калькалаштыру. Интернациональ сүзләр. |
| 4. | Фразеология | 2 | Практ. | Фразеологизмнар турында төшенчә. Фразеологизмнарны төркемләү. |
| 5. | Этимология Лексикография | 4 | Самост. работа | Этимологиянең өйрәнү предметы. Этимологиянең принциплары. Телебезнең сүзлек байлыгы. Сүзләрне сүзлекләргә туплау. Сүзлекләр төзү принциплары. Сүзлекләрнең төрләре. Филологик сүзлекләр. Энциклопедик сүзлекләр. |
| 6. | Ономастика | 2 | Самост. работа | Ономастика фәненең тармаклары: антропонимика, топонимика, зоонимика, космонимика, этнонимика, теонимика, поэтик ономастика. |

## 4. Формы аттестации и оценочные материалы

Форма аттестации – зачёт.

**Список вопросов к зачёту:**

1.Лексика һәм лексикология турында төшенчә.

2.Лексикологиянең тармаклары, лексикологиянең башка тармаклар белән бәйләнеше.

3.Сүз һәм аның асыл сыйфатлары. Сүзнең мәгънәсе һәм төшенчә, алар арасындагы мөнәсәбәт.

4.Сүзнең лексик мәгънәсе һәм аның типлары.

5.Сүзнең күпмәгънәлелеге (полисемия күренеше). Полисемиянең төрләре (метафора, метонимия, синекдоха, функция буенча күчеш).

6.Омонимнар. Аларның төрләре (саф лексик омонимнар, омофоннар, омоформалар, омографлар).

7.Омонимнарның барлыкка килүе.

8.Синонимнар. Синонимик рәтләр, аларда доминанта сүзләр.

9.Синонимнарның төрләре: идеографик, абсолют, стилистик синонимнар, фразеологик синонимнар.

10.Синонимнарның барлыкка килүе һәм телдәге роле.

11.Табу һәм эвфемизмнар.

12.Антонимнар, аларның төрләре: төп антонимнар, ясалма антонимнар, даими һәм контекстуаль.

13.Оксюмороннар. Антитеза.

14.Чыгыш ягыннан хәзерге татар теленең сүзлек составы.

15.Татар теле сүзлек байлыгының төп өлешен тәшкил иткән гомумтөрки лексика. Гомумтөрки лексиканың тематик группалары.

16.Татар телендә гарәп-фарсы алынмалары. Аларның фонетик, морфологик һәм лексик-семантик үзләштерелүе.

17.Татар теленә рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләр, аларның фонетик, морфологик һәм лексик-семантик үзләштерелүе.

18.Татар телендә интернациональ лексика.

19.Кулланылыш сферасы ягыннан татар әдәби теленең сүзлек составы.

20.Гомумхалык теле лексикасы. Диалекталь лексика. Фонетик, морфологик, лексик, семантик, фразеологик, этнографик диалектизмнар.

21.Профессиональ лексика. Жаргон һәм арго сүзләр.

22.Терминологик лексика.

23.Кулланылыш дәрәҗәсе ягыннан татар теленең сүзлек составы.

24.Тарихи сүзләр һәм архаизмнар. Архаизмнарның төрләре: фонетик, морфологик, лексик, семантик. Искергән сүзләрнең әдәби әсәрләрдә кулланылышы.

25.Неологизмнар һәм аларның барлыкка килү юллары. Окказиональ сүзләр.

26.Фразеология, аның өйрәнү предметы буларак фразеологик әйтелмәләр. Фразеологик әйтелмәләрнең төп билгеләре.

27.Татар телендәге фразеологик әйтелмәләрне төркемләү.

28.Фразеологик әйтелмәләрнең барлыкка килүе һәм телдәге әһәмияте.

29.Хәзерге татар теле сүзлек хәзинәсенең экспрессив стилистик катламнары (стильара лексика, көнкүреш сүзләре, китапча сүзләр).

30.Этимология турында төшенчә. Этимологиянең принциплары. Деэтимологизация, реэтимологизация.

31.Лексикография турында кыскача мәгълүмат, аның үсеше. Татар телендәге сүзлекләрнең төп төрләре (энциклопедик, филологик сүзлекләр).

32.Татар лексикографиясе тарихы.

33.Ономастика, аның төп тармаклары.

34.XX гасырның 80-90 елларында татар әдәби теле лексикасының үсүе.

## 5. Учебно-методическое и информационное обеспечение дисциплины:

**Основная литература:**

1.Сафиуллина, Ф.С. Хәзерге татар әдәби теле. Лексикология / Ф.С. Сафиуллина. – Казан: Хәтер, 1999. – 288 б.

2.Сәләхетдинова, З.Ф. Татар теле: Лексикология / З.Ф. Сәләхетдинова, З.Ф. Миргалимова. – Яр Чаллы: Боймиструк, 2009. – 95 б.

**Дополнительная литература:**

1.Галиуллина, Г.Р. татар теле. Лексикология: таблицалар, схемалар, анализ үрнәкләре, күнегүләр / Г.Р. Галиуллина. – Казан: Мәгариф, 2007. – 97 б.

2.Миргалимова, З.Ф. Татар теле практикумы / З.Ф. Миргалимова, З.Ф. Сәләхетдинова, М.К. Юматова. – Казан: Школа, 2008. – 268 б.

**Интернет-ресурсы:**

1.Электронная библиотечная система «Юрайт» - Режим доступа: https://biblio-online.ru/

2.Электронный каталог библиотеки НГПУ. - Режим доступа: http://bibl.ngpi.net:81/cgi-bin/zgate.exe? init+test.xml,simple.xsl+rus

3.Научная электронная библиотека eLIBRARY.RU. - Режим доступа: https://elibrary.ru